Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Масягутовского сельского поселения
Азнакаевского муниципального
района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авылы
җирлеге башкарма комитеты

Ул. Дружбы, д. 12, село Масягутово,
Азнакаевский район, 423321

Дуслык урамы, 12нче йорт, Мәсгут
авылы, Азнакай районы, 423321

Тел. (факс) 8(85592) 38-2-16; e-mail: Msg.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» сентябрь 2019 ел №25

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Мәсгут авыл җирлеге авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, карар чыгарам:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

"Сез 2020 елда үзара салым кертүгә килешәсезме?

Мәсгут авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм катнашучыларының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 400 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметергә, аны 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум итеп билгеләргә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Мәсгут авылы 8 Март, 1 Май, Г. Баһманов урамнары юлларына чуерташ - вак таш җәю;

- Мәсгут, Яхшы-Бай авылларында татар теленә тәрҗемә ителгән юл күрсәткечләрен сатып алу (әзерләү);

- Мәсгут, Яхшы Бай авылларында «Сабантуй», «Яңа ел», «Җиңү көне», «Халыкара хатын-кызлар көне», «Ватанны саклаучылар көне» бәйрәм чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;

- ПУМ 4853 төяү-урып-җыю машинасы өчен КУН-10 төягеч сатып алу (82.1Беларусь тракторы базасында);

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар  аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мәсгут авылы, Дуслык ур., 12 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут  авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык: Габдрахманов Э.Ә.